**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

«20» декабрь, 2022 ел № 39

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге бюджеты турында

Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге бюджеты проектын карап, Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

**1 статья**

1. 2023 елга авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2 404 100,00 сум;

2) авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2 404 100,00 сум.

3) авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профицит) 0 сум күләмендә.

2. 2024 елга һәм 2025 елга авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләме 2024 елга 2 426 200,00 сум һәм 2025 елга 2 467 400,00 сум күләмендә;

2) 2024 елга Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2 426 200,00 сум ;.һәм 2025 елга 2 467 400,00 сум.;

3) 2024 елга авыл җирлеге бюджеты кытлыгы (профициты) 0 сум, 2025 елга 0 сум күләмендә.

3. Авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә:

2023 елга әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2024 елга һәм 2025 елга әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

2. 2024 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2025 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2026 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

**3 статья**

Авыл җирлеге бюджетында 2023 елгаавыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керем күләмен әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына әлеге Карарга 4 нче һәм 5 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен ноль сум күләмендә билгеләргә.

**5 статья**

Авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

2023 елга әлеге Карарга 6 нчы кушымта нигезендә;

2024 елга әлеге Карарга 7 нче кушымта нигезендә;

2025 елга әлеге Карарга 8 нче кушымта нигезендә.

**6 статья**

Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге бюджетында Кукмара муниципаль районы бюджетыннан керә торган бюджетара трансфертларны 2023 нче елга 1 263,10 мең сум, 2024 нче елга 1 267,10 мең сум, 2025 нче елга 1 290,0 мең сум күләмендә исәпкә алырга, шул исәптән:

- муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр 2023 елга 914,70 мең сум, 2024 елга 1099,90 мең сум, 2025 елга 1 116,60 мең сум күләмендә.
- 2023 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына 2023 елга 159,70 мең сум, 2024 елга 167,20 мең сум, 2025 елга 173,40 мең сум күләмендә субвенцияләр;

**7 статья**

Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге башкарма комитеты 2023 һәм 2024 –2025 елларда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

**8 статья**

Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге бюджетыннан авыл җирлеге исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзелгән өчен файдаланылмаган, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2022 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә акча калдыклары, авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2023 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**9 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Кукмара муниципаль районы буенча территориаль бүлеге килешү нигезендә һәм түләүсез нигездә Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**10 статья**

Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**11статья**

Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына элү юлы белән халыкка игълан итәргә.

Җирлек башлыгы: И.М.Нәбиев